ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАКТАЛАЧЫК АВЫЛЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

423751, Такталачык авылы, Г.Афзал ур.,
48 нче йорт.
Тел.:(85552)3-44-57
E-mail:tak-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ТАКТАЛАЧУКСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

423751, село Такталачук,
ул. Г.Авзал,дом 48.
Тел.:(85552)3-44-57
E-mail:tak -akt@yandex.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

20.03.2024 ел. №5

**Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибен, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеген, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибен раслау турында» 2010 елның 2 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Башкарма комитетының 2010 елның 2 апрелендәге 4 номерлы «Муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибен, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеген, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибен раслау турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 4.2 нче пунктта "яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматны күрсәтүне" сүзләрен, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, "белә торып тулы булмаган мәгълүматны күрсәтүне яки белә торып дөрес булмаган мәгълүматны күрсәтүне" сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре булегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе М.Т.Мансуров